ISSN 0136-7110

ЧАЯН



САТИРА ҺӘМ ЮМОР ЖУРНАЛЫ ФЕВРАЛЬ * 2020 * КАЗАН

2



Александр ШУЛЬПИНОВ

АННАН-МОННАН ИНФОРМ

СОҢГЫ ХӘБӘРЛӘР

• Кремль тарафыннан үткәрелгән үзгәртеп корулар нәтиҗәсендә, Шойгу, Лавров, Трамп үз кәнәфиләрендә калдылар.

• Яңа хөкүмәт тәмәке тарта торган махсус зоналар ачарга планлаштырды – Курил утрауларында һәм Беломорканалда.

• Фетнә теориясе тарафдарлары карашынча, хөкүмәтне "Столото" уенында отылган миллиардны халыктан яшерү өчен таркатканнар икән.

• Эстония үзенең хәрбиләрен Ирактан чыгарачагы турында искәрткән. Бары җиде хәрби хезмәткәр өйләренә кайтарылачак.

• АКШ Конгрессы Трампка импичмент ясау яклы. Сенат каршы. Бөтен дөнья уйга калган: соңгы сүзне, гадәттәгечә, рус хакерлары әйтәчәк.

• Ләкләкләр, президентның демография мәсьәләсендәге борчылуын ишетеп, ана капиталыннан өлеш чыгаруын таләп итә.

• Мәктәп яшендәге балалар, әти-әниләренең барлык салымнарын түләгәнлеккә белешмә алып килгәннән соң, кайнар аш белән тәэмин ителәчәк.

• Рәсәйдә чүп реформасы буенча беренче нәтиҗәләр игълан ителгән: халык тутырган, ә коммунальщиклар түкмиләр...

• Сатучылар, сатып алучыларга хезмәт хакларын күтәрүне таләп итеп, митингларга чыккан.

• Украинада Кырымга поезд килү очрагын сәбәп итеп, җинаять эше кузгатылган. Кешеләрне закон бозып чик аша үткәргән өчен паровозга – 15 ел каты режим, вагоннарга 10 ар ел яный.

• Шпагатлар чыгара торган фабрика Волочковага аның йөзе булырга тәкъдим ясаган.

• Яңа ел төнендә Украинада зур масштабта "Оливье" операциясе уздырылган. Аның барышында совет заманы белән элемтә билгесе булган салат сөючеләр тоткарланган.

• Беренче гыйнварны Рәсәйдә Япония көне итәргә дигән тәкъдим ителгән. Чөнки бу көнне байтак рәсәйлеләр японнарга охшаган була.

• АКШта чибәрлек конкурсын берничә үлчәү категориясендә үткәрү күздә тотыла.

• Телевизор караучылар "Зәңгәр огонёк"ны "Зәңгәрләр огонёгы" итеп үзгәртү тәкъдиме белән чыккан.

• WADA карарына җавап йөзеннән, Рәсәй Олимпиадага танк биатлонында җиңүчеләрен җибәрергә әзерлеген белдергән.

• Коммуналь хезмәте быел кышка бик яхшы әзерләнгән – карны һава торышы белдерүеннән үк җыеп калалар.

• Түләүле тире-венерология клиникасы "Дустыңны алып кил – ташлама булачак" дигән акция үткәрә.

• Һава торышы турында: кошларның күптән яшәү урыннарын болай мәгънәсез үзгәрткәннәре юк иде.



ШОМБАЙ *болай диде...*

Хөрмәтле Чаян! ТАССР оештырылуның 100 еллык юбилее алдыннан хакимият татар язучыларына бүләк ясарга булды. Әдәби әсәрләр иҗат итү максатыннан, өч дистә грант булдырылды – романнар өчен ярты миллион, балалар шигырьләре өчен – 50 мең сум. Бу изге башлангыч иҗат әһелләре арасында күп кенә бәхәсләр тудырды. Әсәрләрне гадел рәвештә сайлап алу турында сүз чыкты; язылмаган китаплар өчен түләүнең дөрес булмаганлыгы турында – лаеклыларны укучы үзе билгеләргә тиеш; кайсыбер шигырьнең калын романнан көчлерәк булуы турында һ. б. Чын иҗатчының этәргече акча түгел, ә илһам канатлары булу турында да фикер яңгырады...

М. ШАҺИЕВ

КАЗАН

Без хатны могтәбәр Шомбайга күрсәттек.

– Ахыргысыннан башка, бөтен фикерләр белән дә килешәм, – диде аксакалыбыз. **– Классик әйткәнчә, «илһам сатылмый, тик кульязманы сатып була», ләкин безнең кайбер «классик»ларыбыз илһамын да, кульязмасын да бик шәп сата беләләр...**



Ринат АБЗАЛОВ

Алмаз ХӘМЗИН

НИЛӘР КӨТӘ...

Niləр көтә безне Яңа елда?..
"Бөтен нәрсә яңа булачак!" –
Яңа салым, яңа бәя белән
Дәүләт тагын "куандырачак!"

Һич куркытмый мине болай әйтү,
Чөнки такыр кесә – ришвәтсез.
Ходай каршында чип-чиста мин,
Бер гөнаһсыз, ягъни риясыз.

Намус, вөждан дигән әхлак бетте,
Басты нәфрәт, гауга, алдаулар...
"Тату булыйк!" дигән нотык сөйләп,
Көн-төн сайрый "Дума"дагылар...

Аяк асты тулы нефть дәрьясы,
Газ диңгезе өскә ыргыла,
Тайга шаулый Себер киңлегендә...
Халык талган сагыш моңына.

Нидәр көтә безне Яңа елда?..
Әйе, шул ук куык вәгъдәләр...
Ел дәвамы буе шартлый алар,
Рәнҗеп китә Җирдән адәмнәр...



• • •

Музыка яңгырый. Цирк аренасына баһадир чыга. Ул кулына бер лимон ала да һәм аннан бер стакан сок сыгып чыгара. Арена алкышларга күмелә.

– Моны берәрегез кабатлый аламы? – дип мөрәҗәгать итә залга алып баручы.

Беренче рәттән кечкенә генә буйлы ир кеше күтәрелә. Аны аренага чакыралар. Ул шул ук лимоннан тагын бер стакан сок чыгара. Тамашачы һәм артистның гаҗәпләнүенә чик-чама юк. Артист тыйнак кына елмаеп торучы ирдән сорый:

– Сез кем буласыз соң, тылсым иясе?

– Мин – салым инспекторы!

Ринат АБЗАЛОВ



Хәвефле кәнфитләр

Бөтен дөнья тәмәке тартучыларга каршы, аларны аэропорт, ресторан, хәтта үз балконнарыннан куа-куа көрәшкән арада, сиздермичә генә яңа афәт пәйда булды. Яшүсмерләр арасында «снюс» дигән сәер исем белән аталган никотин кәнфитләренә мода таралды. Кыска гына вакыт эчендә ул, яңалыкка һәвәс яшь буынны үз колачына алып, һәр урам чатында сатыла башлады.

Әлеге дә баягы Интернет та бу шаукымнан читтә калмады, әлбәттә, күз ачып йомганчы иҗтимагый челтәрләрдә бу яманны гади тәмәкене алыштыручы итеп рекламалап, аны яшүсмерләргә ничек файдаланырга өйрәтүче күпсанлы төркемнәр һәм блогерлар барлыкка килде. Кәнфитне тел астыңа саласың да – ләззәт диңгезенә чумасың! Тик рекламачылар ул кәнфиттә никотинның бер кап сигаретка караганда, өч тапкыр артыграк булуы турында – ләм-мим...

Әйтергә кирәк, никотинның мондый күләмдә яшь организмны нинди нәтиҗәләргә китерү мөмкинлеген аңлар өчен, дипломлы наркология белгече булу кирәк түгел. Күрше Башкортстанда 11 яшьлек малай, тел астына снюс салганнан соң, реанимациягә эләккән. Алтай краенда сигезенче сыйныф укучысы белән шул ук хәл: дәрес вакытында аның сулышы тукталган. Ярый әле ашыгыч ярдәм вакытында килеп җиткән. Чаллыда ике мәктәп укучысын өлкән сыйныфтагы бер иптәше снюс белән «сыйлаган». Нәтиҗәдә, балаларның берсе, аңын югалтып, хастаханәгә эләккән. Икенчесенең сөйләвенә караганда, алар даими рәвештә шулай итеп... тренировкалардан соң «ял иткәннәр» икән. Ата-аналары берни дә сизенмәгән: бу кәнфитләрнең исе юк бит...

Чаллы малаен коткарып калганнар, ә менә Липецк өлкәсендә охшаш хәл фаҗига белән тәмамланган: Яңа ел алдыннан 13 яшьлек бала шул ук исерткеч кәнфит белән агуланудан дөнья куйган. Яңа ел дигәннән, Пензада Кыш бабай киеменә киенгән берәү мәктәп балаларына бүләк итеп снюс тараткан...

«Ничек болай килеп чыкты соң? – дип сорар укучы. – Югыйсә инде 2015 елда ук, Татарстан парламенты инициативасы буенча, суыра торган тәмәкене тыю турында федераль закон кабул ителгән иде бит. Һәм ул безне хәвефле катнашмалардан саклап калырга тиеш иде...» Әйе, дөрес, тиеш иде... Ләкин җитештерүчеләр җаен тиз таптылар – «снюс» суыра торганнан чәйни торганга әверелде, табигый тәмәкене синтетик никотин белән алыштырдылар. Ә бердәнбер булган киртәне – балигъ булмаганнарга сатуны тыюны күрмәмешкә салыштылар. Һәм үтерә торган кәнфитләр мәктәпләр, ишегаллары һәм урамнар буенча сәяхәтен башлап җибәрде...

Ул чакта шома сәүдәгәрләрне туктатып булмады. Бу бәланең эпидемиягә әйләнеп баруын узган ел гына абайлап алдылар. Бөтен җирдә диярлек мәктәп укучылары, укулары турында онытып, никотин кәнфите суыра башладылар. Менә шунда инде дәүләт тә, бу мәсьәләдә тәртип урнаштырырга кирәклеген аңлап, «снюс» сатуны тыю турында төгәл төшенчәләргә корылган яңа закон кабул итәргә карар кылды.

Дума әһелләре яңа закон тексты өстендә баш ваткан арада, Татарстанда 5 гыйнвардан балигъ булмаганнарга никотинлы продукция сату тыелды. Минемчә, аны, гомумән, тыю хәерлерәк булыр иде. Барыбер өлкән иптәшләре сатып алып бирәчәк бит. Сыра һәм сигарет шикелле...

Әйтергә кирәк, яңа 2020 елның бер атнасы эчендә генә Роспотребнадзор Татарстанда биш йөздән артык сәүдә ноктасын тикшерде, анда 36 килограмм «снюс» тапты, прокуратура һәм Эчке эшләр министрлыгына утызлап җинаять эше тапшырылды. Бу әле зур эшнең башы гына дип ышандыралар безне аяусыз көрәш алып баручылар. Моны, әлбәттә инде, күптән башларга кирәк иде...

Марат АКСАНОВ



Александр АЛЁШИН

• • •

– Әй малай, тәмәке төпчегеңне чүп савытына ташламыйча, нигә юлга ыргыттың? Нәрсәгә генә өйрәтәләр микән сезне мәктәптә...

• • •

Алтынчы сыйныфта укыганда мине әтием тартып торган чакта тотты. Ул мине сүгеп, кыйнап тормады, бары тик бер кап сигарет алып бирде һәм бөтенесен бер-бер артлы тартып бетерергә кушты.

Шуннан бирле бер капны бушатмыйча, тарту теләген баса алмыйм.

• • •

Әгәр сигарет пачкасында «Тартучы кеше 10 көн буе Интернетка чыга алмаячак» дип язылган булса, никадәр кеше тартуын ташлаган булыр иде...







• • •

– Син беренче тапкыр кайчан үбештең?

– Армиядә. Байрак белән.

• • •

Биш минут буе көлү – бер кашык каймакны алыштыра. Борщка көлегез.

• • •

Шундый гыйбарә бар, иртәнге якта стеналар перфоратор өчен йомшаграк.

• • •

Ишегалдындагы асфальтта "Мин сине яратам!", "Барлыгың өчен рәхмәт!" дигән язулар күрергә мөмкин. Бу бик дөрес: чөнки ишегалдындагы яхшы асфальт бик сирәк очрый торган нәрсә – аны яратмый булмый.

• • •

Әгәр хатын-кыз – серле шкатулка икән, ир-ат инде – әкият белән тулган сандык.

• • •

Ике күрше подъезд баскычында очраша.

– Хәлләрегез ничек, күрше?

– Мактанырлык түгел. Касыкка һәрвакыт нәрсәдер төртә.

– Димәк, бөерләр.

– Син табиб булып эшлисеңме әллә?

– Юк, полицейский мин.

• • •

– Нигә эшкә соңга калдың?

– Башым белән мендәрнең почмагына бәрелгән идем, аңымны югалтып, ике сәгать ятканмын.

• • •

Ире – хатынына:

– Әйдә, рольләр бүлешеп уйныйбыз.

– Ничек?

– Әйтик, син Кызыл Калфак буласың, ә мин – соры бүре. Ризамы?

– Риза.

– Алайса, бар кухняга, пирожкилар пешер!

• • •

Ми 80% сыекчадан тора. Алай гына түгел, күпләрнеке ул тормоз сыекчасы, ә кайберләренә әле җитәрлек итеп салынмаган да була...

Абау!

ЯЛГАН КӨМӘН

Казан фирмаларының берсендә директор булып торучы ханым, авырлы хатыннарга тиеш түләүләрне үзләштереп, баерга булган. Ялган рәвештә авырлы хатыннарны эшкә урнаштырып, кирәкле документларны ясаган һәм алар буенча акча алган. Алар, әлбәттә, булачак аналарга барып җитмәгән, ә директор ханымның кесәсендә утырып калган. Тора-бара, кыюланып, ул авырлы булмаган килеш түләүләрне үзенә дә ясаган. Шулай итеп, шома ханым 5,5 миллион сумны кесәсенә салган.

ДУС-ИШЛӘР БЕЛӘН

Татарстанның Ютазы районы прокуратурасы авария хәлендәге йортларда яшәүчеләрнең күченүләрен тикшергән. Көтмәгәндә кызыклы әйберләр ачыкланган. Бер авыл җирлегенең элеккеге башлыгы бу программага торак хәлен яхшыртуга мохтаҗ булмаган дусларын да керткән. Дус-ишләре белән бергәләп чиновник бюджетны 5 миллион сумга «юкарткан». Ләкин элеккеге башлык, амнистия игълан ителү сәбәпле, җәзадан котылып калган. Әмма урланган акчаны дәүләткә кайтарырга туры килгән.

ПРОБИРКА КАЛҖАСЫ


Казанда ясалма ит һәм балык ясый башлаячаклар. Галимнәр башта лабораториядә республикада аеруча яратылган ат ите ясап карарга җыеналар. Бу юнәлештә эш башланды инде, ләкин «пробирка итен» өч елдан гына татып карарга мөмкин булачак. Ә күпләп җитештерү, ягъни «биологик принтерда» калҗаларны «бастыра» башлаганчы, тагын ике ел үтәчәк. Хәзергә гадәти булмаган иткә караш төрлечә әле. Әмма җор телләр, бу башлангыч тормышка ашырылса, галимнәрдән принтерларда сыйфатлы юллар да бастыруны сорый башларлар дип шаярталар.

КАТЛАУЛЫ ЮМОР

Казан социологлары яшьләрне юмор хисе булу-булмауга тикшергәннәр. Тикшерү көтелмәгән нәтиҗәләр биргән. Мәсәлән, яшь буын мәзәк-анекдотларны, гомумән, аңламый икән. Сүз уйнату, шартлы мәгънә кебек нәрсәләр алар өчен артык каты чикләвек булып чыккан. Ләкин яшьләр арасында мәзәкләр урынын «мем» дигән нәрсә, ягъни көлке рәсемнәр яулап алган. Гадәти юмордан аермалы буларак, аларны аңлар өчен хәтер дә, матур итеп сөйләү сәләте дә кирәк түгел. Ошаган рәсемне иптәшеңә җибәрдең – һәм вәссәлам!



Анастасия ВАСИЛЬЕВА



Виктор ФЁДОРОВ







МИРЗАҺИТ ТОРМЫШЫННАН

Мирзаһит – кала ыгы-зыгысыннан читтә, үз җае белән яшәүче гади авыл кешесе. Башка авылдашлары кебек, ул барча тормыш күренешләренә, катлаулыкларга җиңел карарга өйрәнгән. Мирзаһит беренче карашка гадирәк күренсә дә, аның шаян һәм җор телендә тирән акыл һәм бай тәҗрибә сизелеп тора. Тәкъдим ителгән гыйбарәләр сезгә, бәлки, таныш тоелыр, чөнки һәр авылның үз Мирзаһиты бар бит...

Зөлфәт ШАҺИӘХМӘТОВ

ЯРДӘМ КУЛЫ

Берзаман Мирзаһитка күршеләре пенсия яшенең биш елга артачагы турында хәбәр иткәннәр.

– Менә сиңа кирәк булса! – дигән ул. – Мин бит инде үзем дә сәламәтлегем какшый башлавын сизә башлаган идем. Йә монда авыртып, йә тегендә чәнчеп куя... Алтмыш бишкә кадәр суза алырмын микән дип йөри башлаган идем. Ә монда – көтмәгәндә дәүләт миңа ышаныч белдереп, авыр чакта ярдәм кулы сузды!

ЯШӘҮ ҖИҢЕЛӘЯ

Бер көнне Мирзаһит суелган яшь үгезенең тиресен тапшырырга барган. Кабул итүче аңа тиренең бәясе узган тапкырга караганда кимрәк булачагын әйткән.

Моны ишетеп Мирзаһит елмаеп куйган:

– Бөтенесе «инфляция, инфляция, бөтен нәрсә кыйммәтләнә» дигән булалар. Ә монда киресенчә, арзанлана икән бит. Болай булгач, яшәү дә җиңеләеп китәр әле!

ЯНГА КАЛДЫРГАН

Ял көнендә Мирзаһит, иске чытыр арбасына утырып, хатыны белән шәһәргә – кибеткә киткән. Хатынын кибеттә калдырып, машинасын тын урам читенә куйган һәм көтә башлаган. Шул чакта аның янына бер егет килеп баскан:

– Монда торырга ярамый – түләүле парковка!

Мирзаһит гаҗәпләнеп калган, урамда автобус-мазар йөрми, ул беркемгә дә комачауламый.

– Әгәр дә мин йөреп торсам – моның өчен түлисеме?

– Юктыр... – дип югалып калган егет.

– Ярый, мин киттем алай булгач! – дигән Мирзаһит. Һәм хатыны кибеттән чыкканчы урам буйлап тугыз тапкыр әйләнеп килгән.

– И хуҗалыкчан да инде үзең! – дип мактаган аны хатыны, иренең парковка өчен түләмичә күпме акчаның янга калдырганын белгәч.

Максим СМАГИН



Анастасия ВАСИЛЬЕВА



Исәнмесез, Алмаз абый?..
– Казанга да, "Чаян"га да:
Барчагызга күп сәлам!
Гаделлекне, чынбарлыкны,
Тугры сүз яза каләм!

Нурулла ШӘФИГУЛЛИН

– Исән әле, Нурулла-җан,
Сезнең хәер-догада...
"Чаян" чыгарып ятабыз
Йөз дә илле долларга...

Шигырьләрне күп язгансың, Нурулла, шуларның берсен рәтләп бирәбез.

Алмаз ХӘМЗИН

ДЕПУТАТ ВӘГЪДӘЛӘРЕ

Сайлауга бер атна калгач,
Депутатлар чабыша.
Бәйгеләр узып бара бит –
Халык белән таныша.

Чыгышын ягымлы башлый:
"Сайлау җитте, җәмәгать!
Әгәр мине сайласагыз,
Калырсыз", – ди – канәгать.

Автобуслар йөрми, – дисез, –
Кибет тә юк якында.
Әле сөйләшүләр булыр,
Ясле ачу хакында.

Зарланасыз – "юллар начар" –
Асфальт салып куярбыз,
Шушы якын араларда,
Коймаларны буярбыз.

Пенсиябез бик аз, – дисез –
Арттырырбыз, әлбәттә.
Депутат булу кирәк бит!..
Решим моны – тәхеттә!



"ПРЕСС" АСТЫНДАГЫ ПРЕССА

Хөрмәтле редакция! Безнең тормышыбызда газета-журналлар аерым урын алып тора. Мисал өчен, газетаны алыйк, ул бик күп функцияне башкарырга мөмкин. Әйтик, эссе көнне җилләткеч, чебеннәрне куып, кирәк вакытта – ашъяулык, эсседә – башъяпкыч, килеп терәлсә – кулланмыш... Шул ук вакытта укырга да ярап тора. Шаяруларны куеп торып чынбарлыкка килгәндә, яраткан газета-журналларны хәзер эзләп таба торган да түгел. Татарстан башкаласында зур тизлек белән "Бурычка акча", шаурма лареклары пәйда булса, шундый ук тизлек белән газета-журналлар киосклары юкка чыга бара. Хәзер исә журналның яңа санын табыйм дисәң, тирләп-пешеп шәһәр буйлап эзләп чабасы.

Ә бит 1500 кеше исәбенә бер газета киоскы булырга тиеш дип каралган норма кануннарында. Бу очракта шәһәребез закон тыңламаучан булып чыга түгелме соң? Нибары 0,15 киоск! Иң күп укыла торган пресса "пресс" астыннан чыга алырмы икән дип юрарга гына кала...

А. ГАНЕЕВ

КАЗАН

Александр АЛЁШИН

ЯРДӘМЧЕЛӘР

Трамвай тулы яшь волонтёр,
Картлар йортына бара.
Урын бирүче юк, шуңадыр –
Әби дөбердәп ава.

Алмаз ХӘМЗИН тәрҗемәсе.

Алмаз ХӘМЗИН

КАЙНАР ФИКЕР

Депутатлар сөйли күбрәк
Патриотлык турында.
Үзләренең читтә яши
Кызы белән улы да...

ТАБЫШМАК

Ул элек бар халыкны, эх!
Җырлап юата иде.
Хәзер районнар бюджетын
Сыгып, елата инде!



ХЫЯЛЛАРГА БИРЕЛЕП...

Кадерле Чаян! Хәтерегездә булса, бер классик герой: "Нишләп кешеләр дә кошлар кебек очмый икән?" – дип хыялланган... Әлеге фәлсәфи сорау "Южный парк" торак комплексында яшәүчеләр өчен бик мөһим сорауга әйләнде. Үзегез уйлап карагыз, ул торак комплексы Усад авылыннан ерак түгел урнашкан. Саф һава, машина куяр өчен күп җайлы урыннар, иркен балалар мәйданчыклары, Казанга автобус та җибәрделәр. Рәхәтләнеп, сөенә-сөенә генә яшә инде шунда...

Ләкин андый рәхәтлек төштә генә эләгер сыман. Эш менә нәрсәдә: бөтен кирәкле инфраструктура Усад авылында, ә анда бару өчен Матюшино трассасын үтәсе. Юл хәрәкәте анда бик тыгыз, җәяүлеләргә юлны чыгу өчен юл асты да, юл өсте күпере дә каралмаган. Хәтта шәһәргә бара торган юлны чыкканда зурларга да, укучыларга да үз гомерләрен куркыныч астына куярга туры килә. Менә шул чагында, ирексездән, канатлар турында хыяллана башлыйсың да инде. Әдәбият героинясы кебек, хыяллар трагик рәвештә өзелә күрмәсен дигән уйлар биләп ала. Ни дисәң дә, әлеге йортларны төзегәндә менә шушы фәлсәфи сорау берсененң дә башына кермәгән бит...

Р. МИНДУБАЕВ

УСАДЫ авылы
ЛАЕШ районы

Солдат хәлләре



Игорь КИЙКО

АРМИЯ ГЫЙБАРӘЛӘРЕ

Увольнениедә чакта таныш булмаган кешеләр белән танышмагыз.

Ничек кенә тәртип бозсагыз да, дисциплинага зыян килергә тиеш түгел.

Идәнне көн саен юмасагыз да ярый, тик көненә бер тапкыр булса да кирәк.

Ничек инде баш авырта? Анда бит сөяк кенә, ул авырта алмый!

Күн итекләр кыса? Тар итекләр булмый, зур аяклар була!

«Равняйсь» командасына уң башны борабыз.

Аеруча яшерен документларны укыр алдыннан яндырырга!

Командирга башта «шаяртам» диген, аннан соң гына шаярт.

Сез нәрсә, дөньяга беренче тапкыр тудыгызмы әллә?

Кешечә яшәргә теләмәсәгез, устав буенча яшәрсез!

Александр КОСМЫЛИН



Владимир ТИХОНОВ





«Армиядә минем мондый хәл булган иде...» Гадәттә, кырыс армия хезмәтен уткән ир-егетләр истәлекләрен шул сүзләр белән башлап җибәрә. Бу истәлекләр нинди генә булмасын, алар нарядка йөреп, төн уртасында тревога буенча торып, автомат тотып марш-бросокка чыккан кешеләрдә һәрвакыт елмаю уята.

«САНДУГАЧЛАР»

Безнең полк командиры Татарстанда туган Саба татары, җыр-музыка сөюче кеше иде. Германиядән Ерак Көнчыгышка – җәһәннәм тишегендәге полкка күчерелү белән, ул беренче эш итеп тынлы оркестр җыйды, офицер хатыннарыннан хор оештырды, ә бәйрәмнәрдә бөтенесен дә җыр-биюгә тарта иде. Берзаман ул строевой җыр конкурсы игълан итте. Җиңүче подразделениегә төп бүләк – бер көнгә нарядлардан азат ителү. Мондый кызыксындыру чарасы хакына бөтенесе дә унга ярылырга әзер иде, һәм бөтен полк армиянең мәңгелек репертуарыннан алынган «Идет солдат по городу» ише җырлар өйрәнергә тотынды.

Командирны гаҗәпләндерү һәм башкалардан аерылыр өчен, без – сапёрлар ротасы – нинди дә булса гадәти булмаган нәрсә уйлап чыгарырга булдык. Безнең ротада берничә татар бар иде. Баянчыбыз – Казан егете Рифат Хәлилов сандыгыннан «Татар халык җырлары» китабын табып, аннан «Сарман» көен сайлап алды. Рус туганнарны артык газапламас өчен, беренче куплетын гына ятларга булдык. Вакыт буенча ул нәкъ офицерлар трибунасы алдыннан узар өчен җитәргә тиеш иде.

Смотр көне килеп җитте. Безнең чират. Күн итек табаннарын шакшок итеп, нәчәлникләрдан күз алмыйча, сузып җибәрдек:

Сандугачлар кунып кайда сайрый,
Сарман буйларында тирәктә...

Көч-хәл белән куплетны ерып чыккач, туктап калдык. Кинәт һаваны командирыбызның көр тавышы ярды:

– Молодцы, сандугачлар! Еще раз пройти!

Приказны үтәмичә булмый бит – сайрар сандугачлар турында куплетны сузып, без тагын бер кат трибуна яныннан уздык.

– Еще раз! – дип кычкырды командир, күңел кылларын чирткән җырның дәвамын ишетергә теләп. Өченче тапкыр узганда ул, ниһаять, безнең бер генә куплетны белгәнебезне аңлап алды. Хәйләкәр егетләрне урыннарына утыртыр өчен, ул безне шул җыр белән плацта тагын ярты сәгать йөрергә мәҗбүр итте.

– Вы у меня долго заливаться соловьями будете! – дип җикерде ул трибунадан. Полкташлар тәгәрәп көлде. Шул көннән алып безнең ротаны «сандугачлар» дип кенә атап йөрделәр...

Рамил ИСМӘГЫЙЛЕВ



КАННЫ БЕТЕРҮ

Липецк өлкәсенең Елец шәһәрендә кан бирү станциясен япканнар. Медикларга күп кан алулары һәм аны күрше регионнар белән бүлешергә туры килүе, дәүләткә файдасыз икәнен хәбәр иткәннәр. Станция-не ябып, 12 млн. сум экономия ясау планга кертелгән. Станциянең 2018 елда 58 млн. сум акча эшләгән булуы турындагы дәлилләр түрәләрне ышандырмаган. Медикларны эшсез калдырмаганнар – баш табибка өлкәнең шифаханәсендә 12 мең сум оклад белән табиб эше, ә калганнарга машина йөртүче һәм тракторист вакансияләре тәкъдим иткәннәр.

ЧАКРЫМЛЫ РИШВӘТ

Мәскәүдәге бер бизнесмен танышына эшен үстерү өчен әҗәткә 40 млн. акча биргән. Тегесе акчаны алып качкан. Бизнесмен полиция мөрәҗәгать иткән, тик анда тагын да остарак хәйләкәрләргә юлыккан. Көньяк-Көнчыгыш округының уголовный розыск бүлеге начальнигы һәм оператив хезмәт-кәрләре ярдәм итәргә сүз биргәннәр, әмма бушка түгел. Әҗәтлене эзләп узган һәр чакрым юл өчен тәртип сакчылары 1 мең сум билгеләгәннәр. Һәм бизнесменга якынча 400 мең сумга счет китергәннәр. Акчаны биргәндә "адым санаучыларны" тоткарлаганнар.

ПЕНСИЯДӘН... ТӨРМӘГӘ

Чиләбедә өч пенсионер әби аракы бизнесы белән шөгыльләнергә исәп иткәннәр. Тик кухняда самогон куарга тотынмаганнар, ә зур производство оештырганнар. Әбиләр җирле халыкны эшкә яллаганнар һәм берничә ел тик торган Верхнеуральскның ликеро-водочный заводын эшләтеп җибәргәннәр. Эш уңышлы барган, ярты ел эчендә 7,1 млн. сумга 40 мең шешә аракы чыгарганнар. Бизнесмен әбиләрнең планнарында нәтиҗәләрне тагын да арттыру булган, тик хыялларын полиция хезмәткәрләре җимергән. Тиешле пенсия ялы урынына әбиләргә лаеклы төрмә булачак.

ЯЗМЫШ ИРОНИЯСЕ

Комсомольск-на-Амуре шәһәрендә яшәүче ханым үзенең фатирында йоклап яткан ир-атка тап булган. Полиция чакырткан арада чит кеше юкка чыккан. Хатын-кыз сакчыларга элек үк фатирда кемнеңдер булгалаганын сизгән, тик бернәрсә дә югалмаганын әйткән. Чакырылмаган кунакны тапканнар – ул яшәү урыны булмаган, яшелчә базасында йөк ташучы булып чыккан. Төнлә белән ул эшләгән, ә көндез чит кешенең фатирында йоклаган. Судка зыян күрүче һәм гаепләнүче икесе бергә килгәннәр. Хәзер алар пар булып киткән. Фатир хуҗасы сөяркәсен җәзага тартмауларын сораган, аның төзәлү юлына баскынын белдергән.



Мәгъсүм ГӘРӘЕВ бервөзлексез алтмыш ел радио, газета-журналлар редакцияләре казанында кайный. Төп хезмәтеннән аерылмыйча Казан дәүләт университетының журналистика факультетында укыта.

Мәгъсүм Гәрәев татар әдәбиятында яңа жанр – автопортрет жанрында язып, берсеннән-берсе калын дүрт китап чыгарган зур журналист, язучы, педагог. Шуларның икесе ЮНЕСКОның Париждагы үзәк китапханәсе фондына алынган.

Мәгъсүм Гәрәев 1998 елдан – безнең "Чаян"да әдәбият-сәнгать бүлеге редакторы. 2000 елдан "Мут хикәяләр" циклын ача һәм ун ел дәвамында журналның һәр санында аның шаян-шук язмалары басыла.

Алмаз ХӘМЗИН

МӘГЪСҮМ ГЕРОЙГА!

(юбилей уңаеннан)

Бар әле алар, бар –
Мәгъсүм абыйлар!..
Матбугатны элек
Тоткан шундыйлар!

Үз эшендә алар,
Булдылар – кактус!
Чәнчеделәр барсын:
Түрәме ул, дус?..

Сорап тормадылар
Кемне язарга?!
Ришвәтчеләр күп бит
Безнең заманда...

Кораллары – каләм,
Прокарур – "Чаян"!
Гаепләләр – судта,
Әйтерсең, куян...

"Куяннар" да хәзер
Хәйләкәр төлке –
Төрмәгә керсә дә,
Саклана милке.

Урлыйлар, талыйлар
Яшермичә һич,
Чөнки без аларга
Кеше түгел ич!

Менә шуларны фаш
Итте Мәгъсүмнәр!
Язучы юк беркем, –
Ай-яй, мескеннәр!

ЖУРНАЛИСТ ЯЗМАЛАРЫННАН...

АРАЛАРЫНА КЕРСӘМ!

Аэропорт умарта күчедәй гөж килә. Мәскәүдән самолет көтәбез. Яңгыр сибәләп тора. Шунлыктан космонавт рейсы да кичегә. Ә КГБ безне кисәтә тора:

– Николаев самолеттан төшкәч, әйләнә эченә керү катгый тыела.

Башка тагын кайгы төште. Радио журналистыныкына бигрәк тә. Космонавтның туган ягына кайтып төшкәч әйткән беренче сүзләрен тасмага алмый калсаң, сюжет чыкмый. "Живой голос" кирәк.

Берәр сәгатьтән самолет килеп төште. КГБ, өстәвенә, Мәскәүнекеләр, әйләндереп тә алды аны. Эчтә обком түрәләре генә калды. Чү, тегеннән бер кыз белән егет килә. Кыз кулында бер бөтен ипи, егетнекендә матур чәркә, чуаш сырасы белән. Кадерле кунакны монда шулай каршылыйлар икән. Боларга юл ачык. Урталарында урын бар. Шунда кереп кысылсам, алмаслар әле. Тез буыннары да калтырый калтыравын, барыбер Николаев янына барасым килә. Монысына да кыюлыгым җитте. Андриянның яңгыр астында бер минут чамасы сөйләгән сүзләрен магнитофон тасмасына эләктердем.

Сөенүемнең, куанычымның чиге булмады. "Волга"га утырып сыздырттым Чуашия радиосына. Операторлардан йөзләп язма эшләтеп алдым. Радио, кино, телевидение журналистларына да кирәк бит.

Кичен кунакханәдәге бүлмәм базарга әйләнде. Язманың берсен хәтта Чуашия радиосы егетләренә бер шешә әрмән коньягына саттым. Рәхәтләнеп бергә эчтек.

ЭЛДЕРТ СӘЙДӘШЕ!

Егерменче гасырның егерменче елларында ук танылып, сугыштан соң галәмәт популярлашып киткән бер талант бар иде. Тәбәнәк кенә буйлы, йомран төсле түм-түгәрәк, гаять җитез һәм җыйнак кеше. Дмитрий Покрасс ул – СССРның халык артисты, композитор. Дирижер, музыкант, шәп җырлый һәм тыпырдатып биеп тә җибәрә, чукынган. Сүзгә дә махир бу адәм. Казанга еш килә. Студент чагымда ук концертларына йөри идем мин моның. Хәрби музыкасына үтерә дә куя инде, билләһи. Дмитрий Яковлевич – чын мәгънәсендә сәхнә кешесе, ачык йөзле, шат күңелле, бик тә уенчак. Кирәк чагында клоун да була белә, менә диган тел бистәсе дә.

Кечерәк кенә оркестры "Будённый маршы"н уйнап җибәрә. Әйтерсең, зал җансыз кала. Музыка тынгач, уяна тамашачы, диварлар ярылырлык итеп кул чаба.

Шуннан китә Покрасс абзыебыз тезеп:

– Бу маршмы?! Бу марш өчен миңа Советлар Союзы маршалы Буденный кул сәгате бирде. Алтын сәгать. Әле дә йөри. Менә ул! "Дмитрий Покрасска!" дип язылган.

Музыкантлар "Мәскәү май аенда" дигән көен уйныйлар. Ә ул җырлый:

Май айлары бигрәк матур
Мәскәү калаларында...

Шуннан оркестр җитдиләнә, дирижерның маңгайлары җыерчыклана, ярсуы йөзенә чыга. Яңа музыка. "Әгәр иртәгә сугыш башланса..."

Әнә ул елмая-көлә янә сәхнәгә чыга, бөерләренә таянып зал алдында басып тора: ни көтәсез тагын, концерт бетте, тәмам...

Мин аның янына сәхнә артына менеп китәм. Бер чәкәләшеп аласы килә моның белән.

– Син, малай актыгы, минем белән шаярма. Кара аны, бик телеңә салынасың икән, үзеңне сәнәк белән көлтә урынына эләктердем булыр, – дип кеткелдәп көлә бу, дирижер таякчыгын сәнәк шикелле болгап.

– Мин болай гына, Дмитрий Яковлевич. Будённый сәгате дә. Будённый маршы дип ачуны китерәсең. Безнең татарда Ворошиловтан сәгать алган кеше дә бар бит. Ул да композитор. Маршал алтын кул сәгатен, Кызыл майданда зур хәрби оркестр уйнагач, Мәскәү Кремлендә үзе тапшырган, дип сөйлиләр. "Кызыл Армия маршы"н язган өчен... минем сәхнәгә чыгып, моның белән бер дә мактанганым юк.

Покрассның авырткан җиренә тиде булса кирәк минем сүзләрем. Кабынып китте бу.

– Алып кил иртәгә нотасын, без уйларбыз, син Сәйдәш маршының тарихын сөйләрсең!..

Бирдем мин моңа нота язылган кәгазьне. Саубуллашу концертына Покрасс музыкантлары тәки өлгертте Сәйдәш маршын. Мин, әлбәттә, сәхнәгә күтәрелеп нотык тотмадым. Батырчылыгым җитмәде. Хәер, Сәйдәш музыкасыннан да мәгънәлерәк һәм матуррак нотык була да алмас иде. Рәхмәт йөзеннән композитор Дмитрий Покрассның кулын кысу үзе бер дәрәҗә иде.

Каләмдәшебез Мәгъсүм Гәрәевкә корычтай сәламәтлек, тагын 85 ел яшәвен сорап һәм теләп, гомер бәйрәменең 86 нчысы белән ихлас күңелдән котлыйбыз.

Редакция хезмәткәрләре.



Илдар НӘФИЕВ

КЫЙММӘТ ГОРУРЛЫК

Казанда ир горурлыгында акча эшләмәкче булган уролог хөкем ителгән. Аңа берәү әгъза протезы ясатырга дип мөрәҗәгать иткән. Табиб пациентка бу хезмәт түләүле, ә аңа протезның кирәкле зурлыктагысының ирекле сатуда булмавын аңлаткан. Ир кеше мондый мөһим мәсьәләдә вакланып тормаска булган һәм урология белгеченә 97 мең сум түләгән.

Соңрак ул мондый операцияләрнең бушлай эшләнүен, ә хастаханәдә бөтен кирәкле зурлыкларның булганлыгын ачыклап, бик гаҗәпләнгән. Табибка алган акчаны кире кайтарырга һәм судта үзенең гаебен танып, ике еллык шартлы срок алырга туры килгән.



Алексей МАМАЕВ



Ә МЕНӘ ТАГЫН БЕР МӘЗӘК

• • •

Менә XXI гасырның өченче дистәсе башланды. Өйдә өч телевизор, өч компьютер, өч кесә телефоны һәм бер китап.

• • •

Депутат ерактагы бер авылга барып, кешеләрдән алар өчен нәрсә эшли алуын сораган.

– Бездә ике проблема. Беренчедән, бездә фельдшерлык пункты бар, ләкин фельдшеры юк.

Депутат кесәсеннән телефонын алып, элемтәгә кергән.

– Мин бу мәсьәләне чиштем. Фельдшер монда иртәгә киләчәк. Икенче проблемагыз нинди?

– Безнең авылда кесә телефоны белән сөйләшә алу мөмкинчелеге юк...

• • •

Элек мәктәп укучыларының ике репетиторы бар иде – каеш һәм муен тамыры.

• • •

Табиб:

– Минем ике яңалыгым бар: яхшысы һәм начары.

– Әйдә, башта яхшысын.

– Сезгә пенсия яшенең артуына дулкынланасы түгел...

• • •

ЮХИДИга штраф түләдем. Терминал бөгәрләнгән акчаны алырга теләмәде. Ә менә кешелекле һәм ягымлы гаишник беркайчан да алай эшләмәс иде.


• • •

Минем бабай 73 яшендә дә һәр иртә, кыш булуга карамастан, трусикчан йөгерергә чыга, соңыннан өстенә бозлы су коя. Әби белән аны дәвалыйдәвалый интегеп беттек.

• • •

Белдерү: "Тәҗрибәле актёр, дублёрсыз кәеф-сафа кору күренешләрендә катнашырга әзер!"

Игорь ЛЕВИТИН



Виктор ФЁДОРОВ



Дамир МОРТАЗИН

ЮЛ КЫРЫНДА

Соңгы елларда кешеләр рәхимсезләнде һәм ваемсызланды: бер-берењә ярдәмгә килүләр, булышулар кимеде. Үзләре өчен генә яшиләр сыман…

Әле күптән түгел генә шундый очракка тап булдым, бу инде хәзерге заманның аерылгысыз күренеше. Урам буйлап барам, күрәм, юл кырыенда урамның икенче ягына чыга алмыйча бер әби тора. Мөгаен, андагы ипи кибетенә кермәкче. Янәшәдә генә светофор күренми, җәяүлеләр өчен сызылган полосалар да юк, ә машиналар выжлап үтеп торалар. Нишләсен?.. Аптырап, бер урында таптана, кулында – букчасы. Һич кенә җай таба алмый бит асфальтка басарга…

"Булышырга иде әбекәйгә, – дип уйладым мин. – Югыйсә торачак ул монда үзенең йөз яшьлек юбилее җиткәнче. Кызык, берәр үтүче-китүче игътибарын юнәлтер иде микән аңа, чыгарыр иде микән җитәкләп икенче якка? Табылыр микән әдәпле кеше, ичмасам, берәү, картлыкка хөрмәт белән караучы?"


Туктадым да, һаман күзәтәм. Чамасыз каушаган әбигә күз төшерү дә күңелне елата. Ул чарасызлыктан як-ягына карана, ә үтүчеләр күрми дә…

"Бәлки, алар эшләренә ашыгалардыр, вакытлары юктыр ялгыз әби белән булышырга? – дип уйлап куйдым яңадан.

Сәгатьтән артык вакыт үткәндер, аянычлы күренеш үзгәрмәде. Кем дә булса бу хәлгә игътибар итәргә тиеш иде бит. Ләкин, кызганыч, мескен әбигә мәрхәмәтлелек күрсәтүче табылмады…

Әле байтак карап тордым, бәлки, табылыр шундый әдәпле, миһербанлы, вөҗданлы, кешелекле адәми зат дип. Юк икән шул алар – ышанычым акланмады. Боегып һәм үз-үземнең тынычлыгымны югалтып, мин өйгә таба атладым, ә әбекәйнең салкын җилдә калтыранган гәүдәсе әле бик озак күз алдымнан китмәде…

Михаил ЛАРИЧЕВ



ЮККА ӘЙТМӘСЛӘР

• Телевидение безне белемлерәк итә. Мин үзем тоташтырылган телевизор күрсәм, күрше бүлмәгә кереп китәм һәм китап укый башлыйм.

• Һәр буын аталарыннан көлә һәм бабалары белән горурлана.

• Диктатура ул – барысы берәүдән һәм берәү барысыннан курка торган дәүләт.

• Телевидение ярдәмендә дөнья зур бер авылга әверелде һәм хәзер аның тапшыруларының күбесе авыл гайбәтләренә кайтып кала.

• Караңгылыкны каһәрләгәнче бер кечкенә шәм яндыру хәерлерәк.

• Эш – күңел ачуга караганда, ныграк күңел ачу.

• Хәрби маршлар да, никах маршлары да бер үк нәрсәгә – көрәшкә чакыра.

(акыл ияләре мәҗлесендә язып алынды)

Ринат АБЗАЛОВ

ЯШӘРБЕЗ!

Милләт үлә, диеп лаф оручы
Бушбугазлар, тынып торыгыз;
Читкә чөеп кайнар шигарьләрне,
Тирә-юньгә карап узыгыз.

...Яшь курайчы "Әллүки"не уйный,
Чибәр кызкай суза "Сарман"ны.
Сәхнәләрдә җилпи "Зәңгәр шәл"ләр,
Елый халык, сагынып Илһамны.
Урамнарда – моңлы туган телем,
Мәйданнарда – шигырь бәйрәме,
Өмет гөле – Сабан туйларында
Гореф-гадәтләрнең төс-яме.
Юк, үлмәс ул, газиз туган телем,
Олуг сакчы – халык барында.
"Без туарбыз!", "Без булырбыз!" диеп,
Күпме татар тибә карында...

Яңа туган бала-оныкларга
"Улым", "кызым", диеп дәшәрбез.
Җан-күңелдә һәрчак татар булсак,
Татар булып бергә дөнья корсак –
Татар булып мәңге яшәрбез!

Алексей МАМАЕВ



Александр ШУЛЬПИНОВ





ҮТКӘННӘРГӘ КАРЫЙК КАЕРЫЛЫП

Мөдәррис ӘГЪЛӘМОВ

ТУКАЙГА ЭНДӘШҮ

Исәнме, Тукай!
Жыенып
Килдем бит әле сиңа.
Кемнәрдер минем кулыма
Сал, диеп чәчәк сона.
(Тукайҗан, беләсең инде,
Мин үзем чәчәк сиңа.)

Калтырыйм, куркам,
бу илдә
Ни генә кичермисең.
Өстәвенә, син бит әле
"Мәктәбең ничек", –
дисең,
(Тукайҗан, миңа бит кичә
Бирелгән синең исем.)

Мәктәбең?
Мәктәбем инде
Синдә бит... Туфан, Хәким
Сиңа дип белеп киттеләр.
Ә өстәп нәрсә әйтим?
(Тукайҗан, кяфер илендә
Мин ятим монда, ятим.)

Өстәсәң, өстәрлекләр бар,
Дәүләтем башын сона.
(Тукайҗан,
Ташаягында
Саталар әле сыра.)
И кичер, быел беренче
Зиярәт кылам сиңа.

Син һаман безнең
татарның
Мәктәбе ничек дисең –
Үзгәрми әле мәктәпләр,
Үзгәрә бары исем.
(Тукайҗан, баргач әрнүен
Сөйләр бер Мөдәррисең.)


Сиңа барганчы, кычкырып
Каласы иде бары.
Кычкырсын иде минем күк
Нәкъ миннән соңгылары.
(Тукайҗан, бездә бит әле
Синең сүзеңнең җаны.)

...Хәзергә хуш әле, Тукай,
Сүнмәгән әле утын...
Барып бер зиярәт кылыйм
Син, диеп, Шамил йортын.

1992ел 26 апрель.



Вячеслав БИБИШЕВ, «Чаян» № 22, 1998



Бауржан ИЗБАСАРОВ, «Чаян» № 2, 1979



Виталий ФЕОКТИСТОВ, «Чаян» № 14, 1995

Маннур САТТАРОВ

Хәлләр җыйдым чүгәләп

Ишегалдым түгәрәк,
Уйный сары күбәләк.
Фатир өчен түләү килгәч.
Хәлләр җыйдым чүгәләп.

Кремльнең моржасыннан
Төтен чыга ишелеп.
Чиновникка оклад арткан,
Калганнарга киселеп.

Өстеңдәге күлмәгеңнең
Якаларын кем уйган?
Депутатка, елы чыккач,
Ун пенсия кем куйган?

Поезд килә сызгырып,
Чуен юлны кыздырып.
Район башы пулат салган
Алпавыттан уздырып.

Байлар, байлар бал эчә,
Урта байлар сыра эчә.
Эшләп-эшләп баемаган
Краннардан су эчә.





Рөстәм ЗАРИПОВ

Кармак салып утырганда...

Балык тотып утырганда, вәт әкәмәт, гадәтемчә мәмрәп кителгән, җәмәгать. Кем әйтмешли, тавык төшенә тары керә, имеш ки абзагыз булган текә түрә...

Хатын, мыш-мыш, үз бизнесын алга сөйри, балалар, оныклар көн-төн акча көри. Кода-кодагыйлар, туган-тумачалар бар да сәмән фронтында кайнашалар... Яшәү матур, тормыш көйле, һәр мәл-тәҗел, Форбс китабын иярли безнең нәсел! Багыйм дигәнне баета, кесәң киң тот, кусегә һәм әрләнгә хас инстинкт...

Орден микән, медаль микән тагабыз, дип чакырталар беркөн "өскә" агагызны. Барам. Керәм. Аяк аслармда келәм, атлаганда башмакларым бата тирән... Залның уртасына житкәч, туктап калам, баш әйләнә, калтыранам, дулкынланам... Күрәм, утырышкан илнең хуҗалары. Бар да җитди, баштан ашкан нужалары...

Утыр! – диеп әйтүче юк, торам басып, теләсәң дә булмый моннан чыгып качып. Аптырагач, кай төшнедер куям кашып, кемдер шулчак коры гына куя дәшеп:

– Татарлыкны җилгәрү ник тәмамланмый?! Штатта утыручылар нәрсә карый?..

Исәп-хисап яса җәһәт безнең алда, юкка йөзмәвеңне раслап, майда-балда...

Тамак кырам. Һәр сүземне сайлап кына, сөйләп китәм салмак кына, җайлап кына...

– ...Бу мәсьәлә алты гасыр дәвам итә, чорлар татарлыкны инде күптән тетә... Шаһгалинең тормыш юлы – якты маяк, сәкедән төшкәч, идәндә шуңа аяк. Безгә газиз югарыдан төшкән карар, телгә, моңга хәл кадәри салдык зарар, дуңгызга батырдык татар сәйраннарын, чинаулары күмде былбыл сайрауларын.

Химия сәнәгатенә ачтык урам, өч хәрефле чир котырды мисле буран, һәр өлкәдә җиңеп чыкты рәзилият, адәм көлкесенә калды әдәбият. Почта каулый матбугатны атланып ла, көндәлекләр шуңа күчә атналыкка...

Моргка мәҗбүри бара барча мәет, санитарлар каршы ала колач җәеп, туганнары акча түли ярган өчен, "потроха"сын тунап алып калган өчен... Корьән тәсфирләре чыкты кабартылып, "яратты"сы – "ярaлтты"га яңартылып, русча әйтсәк, "сотворил" "зачал"га күчте, иҗат, функция мөнбәренә төште...

Каты "г", каты "к" юклык зур мәсьәлә, карга – карго, йөк дигән мәгънәгә саба. Къаргъга, дип язып булмагач, аңга үтми, кош турында сүз барганы барып җитми... "Туґъан тль" дип укып булмый, юк, маташма, "туган тел" диеп уеп язылганны ташка. Һәйкәл тиеш, шушы хәлгә мәмнүн затка, филолог доктор, кандидат, депутатка... Къала дип язу ярамый, менә бәла! "Нәҗес – казан"га синоним – "Казан – кала"?.. Әлифбага керткән бозым "аклый" үзен, әмма татар сабыр, әйтми катгый сүзен... Милләтебез өмет өзми, һаман түзә, чаптыр-чоптыр агым уңаена йөзә... ...Шул мәлдә уянып уңга-сулга карыйм, әмма ләкин кармагымны таба алмыйм. Ахры, аңа ару гына балык чирткән, эләккән дә кармагымны сөйрәп киткән. Әллә инде алтын булдымы ул, мине зур түрә итмичә шылдымы ул?..



Ришат МИРЗАЯНОВ



САТИРА ҺӘМ ЮМОР ЖУРНАЛЫ

1923 елдан чыга.

№ 2 (1891) февраль 2020

Баш редактор:
Р. И. ХӘЛИЛУЛЛОВ
Баш рәссам: А. АЛЁШИН
Баш редактор урынбасары: Г. ЗАМАЛДЫНОВА
Үсеш бүлеге: П. СТАРОВЕРОВ
Редакторлар: Р. АБЗАЛОВ,
Л. САФИУЛЛИНА, А. ХӘМЗИН
Сайт редакторы: Л. ӘХМӘТОВА
Корреспондент: Г. СӨНГАТУЛЛИНА
Дизайнер: Л. ФӘЛӘХОВА

Учредителе һәм нәшер итүчесе «ТАТМЕДИА» акционерлык җәмгыяте.

420047, Казан шәһәре, Академическая урамы, 2

Матбугат һәм массакүләм коммуникацияләре агентлыгы ярдәмендә оештырылган.

Журнал Роскомнадзор идарәсендә теркәлде.
Теркәлү саны һәм вакыты:
ПИ № ФС77-44364, 23 март, 2011 ел.

«Журналга «Почта России» каталогы, йә https://podpiska.pochta.ru онлайн аша язылa алалар.

Язылу индекслары:
РТ – П2438 (тат), П2440 (рус);
РФ – П7088 (тат), П7087 (рус).

Редакция материалларны авторларның ризалыгыннан башка редакцияләү-төзәтү хокукына ия.

«ТАТМЕДИА» АҖ филиалы «Идел-Пресс» типографиясендә басылды.
Басылып чыгу: 31.01.2020 ел.
Тираж – 1230 Заказ А-209

Редакциянең адресы: 420066, Казан, Декабристлар ур., 2.

Белешмәләр өчен телефоннар: (843) 222-06-00, 222-05-54.

E-mail: chayan@bk.ru
Сайт: chayan-journal.ru

Бәясе ирекле

16+

Уйна да, уйла да!

ДИРИЖЁР ФОАТ . . .
РАЙОН ҮЗӘГЕ
ФЛАГ, ӘЛӘМ
"СУТЫЙ"
УТЫН ӨЕМЕ
РУС ШАГЫЙРЕ
НОТА
ЯҢА . . . БЕЛӘН!
2020 ел — КҮСЕ . . .
ӨЧ ВЗВОД
"ТРАГЕДИЯСЕ" (ТАКТАШ)
БУЫН
"КҮПЕРЕ ЧҮЕН МӘЛЛӘ, ЧЫЛТЫРЫЙ"
СӘНГАТЬ ТӨРЕ
МӘЗӘК
ИКЕ ТУГАННЫҢ БЕРСЕ
ИҢ РӘХӘТ УРЫН
ТАРТТЫРЫЛГАН ЯРМА
ЭШТӘН СОҢ
"КАРА КАРЛЫГАЧ . . ."
ХУҖАЛЫК КОРЫЛМАСЫ (-2)
НОТА
ОЗЫНЛЫК БЕРӘМЛЕГЕ
"ПАРОХОД"
КЫР ҖӘНЛЕГЕ
ТӘРТИП, ӘМӘЛ
"ТӘНДӘ ҖАНЫМ ТОРСА . . ."
ДИН ӘһЕЛЕ
". . . ПАРГА УТЫРЫП АЙГА ОЧАРМЫН ӘЛЕ"
АНАЛИЗ . . .
АХЫР
ТАШ АТКАНГА . . . АТ
РОССИЯДӘ КИНО ПРЕМИЯСЕ
ОҖМАХТА . . . КЫЗЛАРЫ
МОНСУ ҖЫР АГАЧЫ
САМОЛЁТ
ПИТРӘЧ РАЙОНЫНДА АВЫЛ
АЧ — . . .
ШАГЫЙРЬ . . . РӘХМӘТ
". . . ЛАРЫМКӨЮЛӘРЕМ ГЕЛ СИНЕҢ ӨЧЕН ГЕНӘ"
"ДУС-. . . ЛӘР БЕЛӘН БЕРГӘЛӘП ГОМЕР КИЧЕРСӘҢ ИДЕ"

17 15 9 14 5 12 16 4 7 2 11 3 13 10 1 8 6

Ринат АБЗАЛОВ төзеде



1. Клоун битлеге киеп кереп, кемне бик нык куркытып була?

2. Нәрсә ул ирекле мөнәсәбәт?

3. Аптека дип нәрсәне атыйлар?

4. Нинди костюм беркайчан да модадан чыкмый?

5. Нәрсә ул битне тарттыру?

6. Ни өчен Рәсәйдәге һәр җан башына тиешле керем, алдынгы илләргә караганда, кимрәк?

ҖАВАПЛАР

1. Банк хезмәткәрләрен. 2. Хезмәт хакын өеңә алып кайтып тапшыргач, шуннан соң син ирекле. 3. Бер үк вакытта кеше тормышын озынайта һәм шул ук вакытта кыскарта торган әллә ни максатчан булмаган оешма. 4. Ева костюмы. 5. Колак артына тарттырылган яшьлек. 6. Чөнки безнең һәрберебезнең җаны бар, ә аларныкы юк.

Сынамышларны Гүзәл СӨНГАТУЛЛИНА әзерләде.

Чайнвордны чишегез, номерланган шакмакларда җыр исеме укыгыз. Журналыбызның 1 нче санында басылган чайнвордның тикшерү сүзе – **"БӘГЫРЕМ ДИЯРМЕН".**

Беренче булып дөрес җавап җибәрделәр:

Г. БАҺАВЕТДИНОВ (Чаллы),
Ф. ГАРИПОВА (Сарман.),
Д. ВАСИЛЬЕВ (Әлмәт р-ны, Васильевка ав.),
Б. ШӘЙХЕТДИНОВ (Алексеевский р-ны, Урта Тигәнәле ав.),
С. ШӘЙХУЛЛИН (Казан).

Җиңүчебез – Урта Тигәнәледән
Бәдретдин ШӘЙХЕТДИНОВ!



ЧАЯН ШИФАХАНӘСЕ

ТАБИБ ФИКЕРЛӘРЕ

Офтальмолог: «Беркайчан да күрмәсәм иде шул пациентларны!»

Лор: «Баш табиб бугазымнан тотканчы, колагымны да селкетмәячәкмен!»

Хирург: «Минем өчен иң әһәмиятлесе – авыруның эчке дөньясы».

Терапевт: «Төчкерәм мин сезнең барыгызга да!»

Аллерголог: «Кыйммәтрәк рецепт язып бирергә кулым кычытып тора».

Рентгенолог: «Мин бөтенесен дә үтәли күрәм!»

Дерматолог: «Мондый хезмәт хакына тиреләреннән башкалар чыксын».

Венеролог: «Тормыш күрсәткәнчә, сөю беркайчан да картаймый».


Проктолог: «Бездә бөтен нәрсә дә минем һөнәр өлкәсе аша бара».

Патологоанатом: «Минем пациентларым беркайчан да шикаять язмаячак».


Сергей АНДРИАНОВ



Василий АЛЕКСАНДРОВ



Виктор ФЁДОРОВ



4612750670080